ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КҮЗКӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

КАРАР

«15» март 2024 ел Күзкәй авылы № 2

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге составына керүче Яңа Байлар авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 27 октябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына һәм 2023 елның 27 октябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге Яңа Байлар авылында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге Яңа Байлар авылында гражданнар җыенын билгеләү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Тукай муниципаль районы «Күзкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Күзкәй авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында» нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге Советының 2019 елның 05 ноябрендәге 10/1 номерлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге составына керүче Яңа Байлар авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 27 октябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына һәм 2023 елның 27 октябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге Яңа Байлар авылында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча 2024 елның 28 мартына 09.00 сәгатькә гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез үзгәрешләр кертергә ризамы:

1) түбәндәге редакциядә бәян итеп, гражданнар җыенына чыгарылган һәм кабул ителгән «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге составына керүче Яңа Байлар авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 27 октябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына:

«- торак пункт территориясен төзекләндерү»;

2) түбәндәге редакциядә бәян итеп, 2023 елның 27 октябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге Яңа Байлар авылында гражданнар җыены карарына:

«- торак пункт территориясен төзекләндерү».

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Күзкәй авыл җирлеге, Яңа Байлар авылы, Октябр ур., 18Г йорт (фельдшер-акушерлык пункты бинасы).

4. Халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә махсус мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarsatan.ru) урнаштырырга.

6. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Тукай муниципаль районы
Күзкәй авыл җирлеге Башлыгы Э.Р. Гәрәев